ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.07.2021 Казан ш. № 128-4/соц-2021

«Гомер өчен кирәкле һәм мөһим булган дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларын җитештерүчеләр тарафыннан билгеләнгән чынлыкта сатып җибәрү бәяләренә күмәртәләп һәм ваклап сату өстәмәләренең чик күләмнәрен һәм ваклап сату өстәмәләренең чик күләмнәрен билгеләү турында» 19.02.2010 №8-1/соц Татарстан Республикасы Тарифлар буенча комитеты карарына үзгәреш кертү хакында

Норматив хокукый актны актуальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

«Гомер өчен кирәкле һәм мөһим булган дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларын җитештерүчеләр тарафыннан билгеләнгән чынлыкта сатып җибәрү бәяләренә күмәртәләп һәм ваклап сату өстәмәләренең чик күләмнәрен һәм ваклап сату өстәмәләренең чик күләмнәрен билгеләү турында» 19.02.2010 №8-1/соц Татарстан Республикасы Тарифлар буенча комитеты карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 21.08.2010 №8-3/соц карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) прембуласына үзгәреш кертеп, аны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Дару чараларын әйләнештә йөртү турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы, «Гомер өчен кирәкле һәм иң әһәмиятле дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына бәяләрне дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2010 елның 29 октябрендәге 865 номерлы, «Гомер өчен кирәкле һәм иң әһәмиятле дару чараларына бәяләрне дәүләт тарафыннан җайга салуны камилләштерү турында» 2009 елның 8 августындагы 654 номерлы карарлары, Россия Федераль тарифлар хезмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары тарафыннан гомер өчен кирәкле һәм иң әһәмиятле дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына дару препаратларын җитештерүчеләр билгеләгән фактик сатып җибәрү бәяләренә

күмәртәләп сатуда чик дәрәҗә өстәмә һәм ваклап сатуда чик дәрәҗә өстәмә бәяләр билгеләү методикасын раслау турында» 2020 елның 9 сентябрендәге 820/20 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе КАРАР БИРӘ:».

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В.Хабибуллина